ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

6 февраль, 2020 ел № 36/5

Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең
һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү
шартлары турында

«Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 1 ноябрендәге 998 номерлы Карары, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде

1. Расларга:

1) «85 нче психологик-медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә;

2) «85 нче психологик-медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфалары, эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә.

2. Яр Чаллы шәһәренең «Муниципаль учреждениеләрне җитештерү-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль автономияле учреждениесендә җитәкчеләр һәм хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/7 номерлы Карары белән расланган аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәнең 3 бүлеге нигезендә башкарыла дип билгеләргә.

3. Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/7 номерлы Карары (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/8, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/10,

2019 елның 23 маендагы 31/6 номерлы Карарлары редакциясендә ) белән расланган аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле 21.2 пункт өстәргә:

«21.2 Аерым муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициенты:

| Вазыйфаның исеме | Коэффициент | Вазыйфаи оклад күләме-сумнарда |
|---|---|---|
| Архив мөдире, өлкән инспектор, машинада бастыру бюросы мөдире, күчермә ясау - күбәйтү бюросы мөдире, инспектор, статистик, хуҗалык мөдире, склад мөдире, кассир, комендант, эш башкаручы, архивариус, стенографист, секретарь-стенографист, машинистка, экспедитор, секретарь-машинистка, җитәкче серетаре, таксировщик, участок мастеры (шул исәптән өлкән белгеч) | 1,0 | 11 163» |

2) 26 пунктның таблицасына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| «Автослесарь, автоэлектрик, аккумуляторчы, моторчы, шиномонтажчы | 4-5 |
| Машина йөртүче, слесарь-ремонтчы | 9-10» |

3) 27 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмә түләү – 50 процент күләмендә; «машина йөртүче» вазыйфасы буенча-75 процент күләмендә;»;

4) 27 пунктның 6 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«аеруча мөһим биремнәрне үтәүче машина йөртүчеләргә хезмәт интенсивлыгы өчен түләү вазыйфаи окладның 150 проценты күләмендә.».

4. Әлеге Карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә, Карарның 1 пункты 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш һәм бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
36/5 Карарына
1 нче кушымта
6 февраль, 2020 ел

Нигезләмә
«85 нче психологик-медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә «85 нче психологик-медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – аерым мәгариф оешмалары) хезмәткәрләре өчен окладларны формалаштыру тәртибен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләү шартларын һәм күләмен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

2. Аерым мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы (хезмәткә түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

1) вазыйфаи окладлар;
2) компенсация характерындагы түләүләр;
3) кызыксындыру характерындагы түләүләр.

3. Аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәре, мәдәният хезмәткәре, медицина хезмәткәренең профиль буенча эш стажы артуга, белем алуга яки белем турындагы документларны яңадан торгызуга, квалификация категориясен бирүгә, мактаулы исем бирүгә, ведомстводың аерым хөрмәтләү билгеләре белән бүләкләнүгә бәйле рәвештә, ел саен бирелә торган яки башка ял вакытында, вакытлыча эшкә яраксызлык чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларда хезмәт хакы күләме үзгәрүгә хокукы күрсәтелгән чордан соң гамәлгә ашырыла

## 2 бүлек. Аерым мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

4. Аерым мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Айлык база окладЫ күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналның һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Уку бүлеге секретаре | 9 489 | 9 868 | - |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналның һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Кече тәрбияче | 9 550 | 10 015 | - |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча инструктор | | 11 680 | 14 200 |
| | Музыка җитәкчесе | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Педагог-оештыручы | - | 11 687 | 14 220 |
| | Социаль педагог | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Тәрбияче | - | 11 693 | 14 232 |
| | Педагог-психолог | | | |
| | Өлкән инструктор-методист | | - | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Методист | | | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 14 236 |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | | | |
| | Укытучы-дефектолог | | | |
| | Укытучы-логопед (логопед) | | | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешмалар, гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы структур бүлекчә (бүлек, лаборатория, бүлек, сектор, укыту-консультация пункты, укыту-җитештерү остаханәсе һәм башка структур бүлекчәләр) мөдире (башлыгы) (икенче квалификация дәрәҗәсенә караган структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | - | - | 14 301 |

4. Аерым мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Айлык база оклады күләме, сумнарда | |
|---|---|---|
| | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Аккомпаниатор | 10 000 | 10 300 |
| Түгәрәк, һәвәскәрләр берләшмәсе, клуб җитәкчесе | | |
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Китапханәче | 10 500 | 13 000 |
| Тавыш операторы | | |

6. Аерым мәгариф оешмалары медицина хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Айлык база оклады күләме, сумнарда | |
|---|---|---|---|
| | | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Медицина регистраторы | 10 000 | - |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 11 000 | - |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы | 12 700 | - |
| Табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәсенә караган табиб-белгечләрдән тыш) | - | 14 200 |

7. Мәгариф хезмәткәрләрен, мәдәният хезмәткәрләрен, медицина хезмәткәрләрен җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының Бердәм квалификация белешмәсе яисә һөнәри стандартлар белән билгеләнгән белем дәрәҗәсеннән түбән булган вазыйфаларда кабул иткән очракта, мондый хезмәткәрләргә база оклады таләп ителгән белем дәрәҗәсе нигезендә билгеләнә.

8. Мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең белем дәрәҗәсе җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының Бердәм квалификация белешмәсе белән билгеләнгән дәрәҗәдән югары булса, мондый хезмәткәрләргә база оклады таләп ителгән белем дәрәҗәсе нигезендә билгеләнә.

9. Мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең эш вакыты (хезмәт хакы ставкасы өчен эш сәгате нормалары) Россия Федерациясе Хезмәт кодексы белән билгеләнә.

10. Аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_{fk}}{H_N} + P,$$

монда:

$O_d$ - аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;

$O_b$ - аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең база окладлары күләме;

$H_{fk}$ - аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре эш сәгатьләренең факттагы эшләнгән саны;

$H_N$ - мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең, аерым мәгариф оешмаларының медицина хезмәткәрләренең Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган эш вакытының дәвамлылыгы;

P-китап басу продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация, педагогик хезмәткәрләргә укыту йөкләнешенә пропорциональ, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаган күләмдә билгеләнә.

11. Педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри-квалификация төркеменә керүче мәгариф хезмәткәрләренә (алга таба - педагогик хезмәткәрләр) аудиториядән тыш эш белән мәшгульлек өчен түләүләр үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1) уку кабинетлары, лабораторияләр, музейлар белән идарә иткән өчен түләүләр;

2) фән, методик яки цикл комиссиясе, методик берләшмәләргә җитәкчелек иткән өчен түләүләр.

12. Уку кабинетлары, лабораторияләр, аерым мәгариф оешмаларының музейлары белән идарә иткән өчен түләү 444 сум тәшкил итә.

Кабинетлар, лабораторияләр җитәкчелеге уку-укыту-методик, дидактик һәм күрсәтмә материалның уку кабинеты паспортының белем бирү процессын

җиһазлауга карата расланган таләпләрнең кимендә 50 процентына туры килүе дәрәҗәсендә билгеләнә

Педагогик хезмәткәр тарафыннан берничә уку кабинеты, лаборатория, музей эше тәэмин ителгәндә күрсәтелгән эшне тәэмин иткән өчен түләү күләме һәр уку кабинеты, лаборатория, музей буенча түләүләр суммасында исәпләнә.

13. Предмет, методик яки цикл комиссияләре, методик берләшмәләр белән җитәкчелек иткән өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә::

$$B_{nz}^{rk} = O_b \times D_{rk},$$

монда:

$B_{nz}^{rk}$ фән, методик яки цикл комиссиясе, методик берләшмәләргә җитәкчелек иткән өчен түләүләр;

$O_b$-аерым мәгариф оешмалары педагогик хезмәткәрләренең база оклады күләме;

$D_{rk}$ - предмет, методик яки цикл комиссияләре, методик берләшмәләр белән җитәкчелек иткән өчен өстәмә түләү күләме 3 процент тәшкил итә.

Gедагогик хезмәткәр берничә комиссия, берләшмә белән җитәкчелек иткәндә түләү күләме һәр комиссия, берләшмә буенча түләүләр суммасы буларак исәпләнә.

## 3 бүлек. Кызыксындыру характерындагы түләүләр

14. Кызыксындыру характерындагы түләүләргә мәгариф хезмәткәрләрен, мәдәният хезмәткәрләрен, медицина хезмәткәрләрен сыйфатлы хезмәт нәтиҗәләренә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

15.Кызыксындыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) квалификация категориясе өчен түләүләр;
2) эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;
3) дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр;
4) профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;
5) интенсив хезмәт өчен түләүләр;
6) премия һәм башка кызыксындыру түләүләре;
7) башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр.

16. Квалификация категориясе өчен түләүләр мәгариф хезмәткәрләренә, гамәлдәге квалификация категориясе булган очракта, квалификация категориясе гамәлдә булу срогы чикләрендә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \text{ x } D_{kk},$$

монда:

$B_{kk}$ - квалификация категориясе өчен түләүләр;

$O_d$-аерым мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$-квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме педагогик хезмәткәрләр | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 5,0 |
| | югары квалификация категориясе | 6,0 |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 6,0 |
| | югары квалификация категориясе | 8,0 |
| Өченче | беренче квалификация категориясе | 6,5 |
| | югары квалификация категориясе | 10,0 |
| Дүртенче | беренче квалификация категориясе | 8,0 |
| | югары квалификация категориясе | 12,0 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме структур бүлекчәләр җитәкчеләре | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 6,0 |
| | югары квалификация категориясе | 8,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән башкарыла.

17. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sop} = O_d \times D_{sop},$$

монда:

$B_{sop}$ -эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;

$O_d$-аерым мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sop}$- эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр күләме.

Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме

| Тәртип номеры | Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү билгеләү өчен нигез | Һөнәри-квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Гаиләгә ярдәм итү үзәкләрендә эш | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | икенче-дүртенче | 23,5 |
| | | структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | беренче | 6,0 |

18. Беренче һәм икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналга, педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәгариф хезмәткәрләренә Совет Социалистик Республикалар Союзы, Россия Федерациясе, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикалар, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә::

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

монда:

$B_{pz}$-дәүләт бүләкләре өчен түләүләр;

$O_d$-аерым мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$-дәүләт бүләкләре өчен өстәмә түләү күләме.

Россия Федерациясе, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикалар дәүләт бүләкләре өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре (Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы) өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе, Россия федератив Социалистик Республикасы, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалары Союзы, Совет Социалистик Республикалары Союзы составында союздаш республикалары тармак бүләкләре өчен өстәмә түләү күләме 4 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең Мактау грамотасы өчен өстәмә түләү күләме 2 процент тәшкил итә. Россия Федерациясенең Мактау грамотасы өчен өстәмә бүләкләнүче мәгариф хезмәткәрләренә Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының) ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә Россия Федерациясе мәгариф министры (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры, Россия Федерациясе мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.

Татарстан Республикасының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе өчен өстәмә түләү күләме 2 процент тәшкил итә. «Мәгарифтәге казанышлары өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе өчен өстәмә түләү Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.

Мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган дәүләт һәм ведомство бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында китерелгән.

Дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү күләмен билгеләү дәүләт бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләкләренә ия булган мәгариф хезмәткәрләренә алар өчен түләү, мәгариф хезмәткәре сайлавына карап, дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

19. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри-квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә::

$$B_s = O_d \text{ x } D_s,$$

монда:

$B_s$-профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$-аерым мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладыо;

$D_s$-профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме 3 нче таблицада китерелгән.

3 нче таблица

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме

| Һөнәри-квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|---|
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | беренче-икенче | 4 елдан 10 елга кадәр | 1,0 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,0 |
| | | 15 елдан артык | 3,0 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | беренче - дүртенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 2,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 3,0 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | | 15 елдан артык | 4,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | беренче - өченче | 2 елдан 6 елга кадәр | 2,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 3,0 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | | 15 елдан артык | 4,0 |

Эш стажын үзгәрткәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү) стажга, стажны раслаучы документлар оешмада булса, эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ия булган көннән яки стажны раслый торган документ бирелгән көннән башкарыла.

20. Мәгариф һәм башка оешмаларда педагогик, җитәкче һәм методик эш педагогик эш стажына керә һәм 4 нче таблица нигезендә исәпләнә.

4 нче таблица

Эш вакыты мәгариф хезмәткәрләренең педагогик стажына кертелә торган оешмалар һәм вазыйфалар исемлеге

| Оешма исеме | Вазыйфаның исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Белем бирү оешмалары (шул исәптән югары белем бирү оешмалары, югары (урта) хәрби белем бирү оешмалары), өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары (белгечләрнең квалификациясен күтәрү), социаль хезмәт күрсәтүче медицина оешмалары һәм оешмалары (бала йортлары, балалар шифаханәләре, шулай ук балалар өчен оешмалар, өлкәннәр өчен оешмалардагы балалр бүлекләре һәм палаталары) | Укытучылар, укытучы- дефектологлар, укытучылар-логопедлар (логопедлар), укытучы-оештыручылар (тормыш иминлеге нигезләре, армиягә кадәрге әзерлек нигезләре), физик тәрбия җитәкчеләре, өлкән мастерлар, производствога өйрәтү мастерлары (шул исәптән транспорт чараларын йөртергә, авыл хуҗалыгы машиналарында эшләргә өйрәтү, язу машиналарында һәм башка оештыру техникасында эшләргә өйрәтү), өлкән методистлар, методистлар, өлкән инструктор-методистлар, инструктор-методистлар (шул исәптән физик культура һәм спорт, туризм буенча), концертмейстерлар, музыка җитәкчеләре, өлкән тәрбиячеләр, сыйныф тәрбиячеләре, социаль педагоглар, педагог-психологлар, педагог-оештыручылар, өстәмә белем бирү педагоглары, өлкән тренер-укытучылар, тренер-укытучылар, өлкән әйдаманнар (пионервожатыйлар), физкультура инструкторлары, хезмәт инструкторлары, директорлар (башлыклар, мөдирләр), укыту, укыту-тәрбия, укыту-производство, тәрбия, мәдәни-тәрбия эшләре, җитештерү буенча укыту (эш), чит тел буенча, укыту- |

| | |
|---|---|
| | очучылар әзерләү, гомуми белем бирү әзерлеге буенча, режим буенча директор урынбасарлары (башлыклар, мөдирләр), уку-укыту бүлеге мөдирләре,(башлыклары): практика, укыту-консультация пунктлары, логопед пунктлары, эшчәнлеге белем бирү (тәрбия) процессы, методик тәэмин ителеш белән бәйле булган башка структур бүлекчәләр, интернатлар, бүлекләр, бүлекләр, лабораторияләр, кабинетлар,секцияләр, филиаллар, курслар һәм башка структур бүлекчәләр, режим буенча өлкән дежурлар, режим буенча дежурлар, аккомпаниаторлар, мәдәни оештыручылар, экскурсоводлар; профессор-укытучылар составы; |
| Барлык исемдәге методик (укыту-методик) оешмалар (ведомство буйсынуына карамастан) | Җитәкчеләр, аларның урынбасарлары, сектор, кабинетлар, лабораторияләр, бүлекләр мөдирләре; эшчәнлеге методик тәэмин ителеш белән бәйле фәнни хезмәткәрләр; өлкән методистлар, методистлар |
| Мәгариф белән идарә итү органнары һәм мәгариф оешмалары белән җитәкчелек итүче органнар (структур бүлекчәләр) | Җитәкче, инспекторлык, методик вазыйфалар, инструкторлык, шулай ук белгечләрнең башка вазыйфалары (икътисад, финанс, хуҗалык эшчәнлеге, төзелеш, тәэмин итү, эш башкару белән бәйле вазыйфаларда эшләүдән тыш) |
| Производствога кадрлар әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче оешмалар, министрлыклар (ведомстволар) бүлекчәләренең техник укыту бүлекләре (бюролары), кадрлар бүлекләре | Штаттагы укытучылар, җитештерүдә эшчеләрне производствога өйрәтү мастерлары, эшчәнлеге әзерлек һәм квалификация күтәрү мәсьәләләренә бәйле җитәкче, инспектор, инженер, методик вазыйфалар |
| Россия оборона спорт-техник оешмасы (армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте) һәм гражданнар авиациясенең белем бирү оешмалары | Җитәкче, команда-очу, команда-инструктор, инженер-инструктор, инструктор, инструктор һәм укытучылар составлары, производствога өйрәтү мастеры, борт инженер-инструкторлары, очу әзерлеге буенча методистлар (борт инженерлары, борт операторлары, борт радистлары, икенче пилотлар, һава суднолары командирлары, штурманнар) |
| Предприятиеләр һәм оешмаларның тулай торакклары, торак-эксплуатация оешмалары, яшьләр торак комплекслары, балалар кинотеатрлары, яшь | Тәрбиячеләр, педагог-оештыручылар, педагог-психологлар (психологлар), балалар һәм яшүсмерләр өчен өстәмә белем бирү педагоглары (түгәрәк җитәкчеләре), инструкторлар һәм инструктор-методистлар, тренер-укытучылар һәм балалар һәм |

<table>
<tr><td>тамашачы театрлары, курчак театрлары, мәдәни-агарту оешмалары һәм предприятие һәм оешмаларның балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү буенча бүлекчәләре</td><td>яшүсмерләр белән эшләү буенча башка белгечләр, балалар бүлекләре, секторлар мөдирләре</td></tr>
<tr><td>Төзәтү колонияләре, тәрбия колонияләре, тикшерү изоляторлары һәм төрмәләр, дәвалау-төзәтү оешмалары</td><td>Педагогик белем булганда эш (хезмәт) вазыйфаларда: тәрбия эшләре буенча башлык урынбасары, отряд башлыгы, өлкән инспектор, гомуми белем бирү (укыту) буенча инспектор, өлкән инспектор-методист һәм инспектор-методист, техник белем бирү буенча өлкән инженер һәм инженер, производствога өйрәтү буенча өлкән мастер һәм мастер, хезмәтне саклау һәм режим буенча өлкән инспектор һәм инспектор, укыту-техник кабинет мөдире, психолог</td></tr>
<tr><td colspan="2">Искәрмә:<br>Педагогик эш стажына кертелә:<br>өлкәннәр өчен социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмаларда һәм медицина оешмаларында укытучы-дефектолог, логопед, тәрбияче, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау оешмаларының оештыру-методик бүлеге методистлары булып эшләү вакыты;<br>Совет Социалистик Республикалар Союзы һәм Россия Федерациясенең Кораллы Көчләрендә хезмәт итү, югары белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча түбәндәге тәртиптә уку вакыты:<br>педагогик хезмәткәрләргә педагогик эш стажы бернинди шартлар һәм чикләүләрсез исәпләнә:<br>контракт буенча хәрби хезмәт үтү вакытында - бер хәрби хезмәт көне бер көн эш көне , хәрби чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булу вакыты - бер хәрби хезмәт көне ике хезмәт көне хисабыннан;<br>фильмотека мөдире һәм фильмотека методисты вазыйфасында эшләү вакыты;<br>аерым яки гомуми алганда, түбәндәге чорларга кадәр һәм аннан соң педагогик эшчәнлек алып барылган очракта педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажында түбәндәге чорлар исәпкә алына:<br>Совет Социалистик Республикалар Союзы һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә офицер, сержант, старшина составларында прапорщиклар һәм мичманнар (шул исәптән Эчке эшләр министрлыгы гаскәрләрендә, куркынычсызлык органнарында һәм гаскәрләрдә) вазыйфаларында контракт буенча һәм чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булу вакытыннан тыш, хезмәт итү вакыты;<br>Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре профсоюзының (агарту, югары мәктәп һәм фәнни оешмалар) территориаль оешмалары аппаратларында (комитетларда, советларда) белгечләрнең җитәкче, инспекторлык, инструкторлык һәм башка вазыйфаларында; профсоюз органнарында сайланулы вазыйфаларда; педагогик җәмгыятьләрдә һәм Балалар фонды идарәләрендә инструкторлык һәм методик вазыйфаларда; Укытучы(халык мәгарифе, һөнәри техник белем бирү хезмәткәре) йорты директоры (мөдире) вазыйфасында; балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның</td></tr>
</table>

| |
|---|
| хокукларын яклау комиссияләрендә яки балигъ булмаганнарны социаль-хокукый яклау бүлекләрендә, Эчке эшләр органнарының хокук бозуларны кисәтү бүлекчәләрендә (балигъ булмаганнар эшләре буенча инспекция, милициянең балалар бүлмәсе) эшләү вакыты |

21. Аерым категория педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажына Совет Социалистик Республикалар Союзының һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү һәм оешмаларда белем бирү оешмасындагы эш юнәлешенә яки укытыла торган фәннең (курс, дисциплинаның, түгәрәкнең) профиленә туры килә торган эш чоры исәпләнә:

1) укытучы-оештыручыларга (тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләре, армиягә кадәр әзерлек нигезләре);

2) физик тәрбия укытучыларына, физик тәрбия җитәкчеләренә, физкультура инструкторларына, инструктор-методистларга (өлкән инструктор-методистларга), тренер-укытучылага (өлкән тренер-укытучыларга);

3) укытучыларга, хезмәт (һөнәр) укытучыларына, технология, сызым, сынлы сәнгать, информатика, махсус фәннәр, шул исәптән аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле гомуми белем бирү оешмаларының (сыйныфларының) махсус фәннәр укытучыларына;

4) өстәмә белем бирү педагогларына;

5) эксперименталь белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә;

6) педагог-психологларга;

7) методистларга;

8) музыка һәм сәнгать гомуми белем бирү оешмаларының махсус фәннәре укытучыларына.

22. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, балалар йортлары тәрбиячеләренә (өлкән тәрбиячеләренә) педагогик стажга мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының ясле төркеменең шәфкать туташы, балалар йортларының пост шәфкать туташлары, ясле төркеме тәрбиячеләренә - медицина вазыйфаларында эшләү вакыты кертелә.

Тәрбияче ярдәмчесе һәм кече тәрбияче вазыйфаларында эшләү вакыты, әлеге вазыйфаларда эшләгән чорда хезмәткәрнең педагогик белеме булган, яки ул югары белем бирү оешмасында яки һөнәри белем бирү оешмасында укыган очракта, педагогик эш стажына исәпләнә.

Оешма хезмәткәрләренең педагогик эш вакыты мәгариф оешмаларында төп эш урыныннан тыш сәгатьләп түләү шартында эшләнгән эш күләме(бер яки берничә белем бирү оешмасында), уку елы дәвамында 180 сәгатьтән дә ким булмаса, педагогик стажга кертелә.

Шул ук вакытта педагогик стажга педагогик эш башкарган айлар гына кертелеп исәпләнә.

Совет Социалистик Республикалар Союзы һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә эшне оештыру һәм хезмәт итү фән (курс, дисциплина, түгәрәк) укытыла торган эш профильләренә туры килү-килмәү турындагы конкрет мәсьәләләрне хәл итү хокукы профсоюз оешмасы җитәкчесенә бирелә.

Квалификация категориясе өчен түләүләр тариф-квалификация характеристикасы нигезендә һөнәри-квалификация төркемнәре киселешендә

аттестация нәтиҗәләре буенча квалификация категорияләрен бирүне күздә тоткан белгечлекләр буенча мәгариф оешмалары мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

монда:

$B_{kk}$ - квалификация категориясе өчен түләүләр;

$O_d$-аерым мәгариф оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$-квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме 5 нче таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (оешма) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

5 нче таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме

| Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация категориясе | 5,0 |
| Югары квалификация категориясе | 8,0 |

24. Дәүләт бүләкләре өчен түләүләр мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

монда:

$B_{pz}$-дәүләт бүләкләре өчен түләүләр;

$O_d$-аерым мәгариф оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$-дәүләт бүләкләре өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автономияле республикалар дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикалар дәүләт бүләкләре өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган дәүләт бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында китерелгән.

Дәүләт бүләкләренә ия булган өчен тиешле түләү күләмен билгеләү дәүләт бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләкләре булган хезмәткәрләргә түләү, хезмәткәр сайлавы нигезендә, шуларның берсе буенча билгеләнә.

25. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр, хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларының үтәлешен исәпкә алып, профиль буенча эш дәвамлылыгына карап, һөнәри-квалификация төркемнәре киселешендә, аерым мәгариф оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә::

$$B_s = O_d \times D_s,$$

монда:

$B_s$-профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$-аерым мәгариф оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$-профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме 6 нчы таблицада китерелгән.

6 нчы таблица

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме

| Һөнәри-квалификация төркеменең исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|
| Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 1,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,0 |
| | 15 елдан артык | 2,5 |
| Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 2,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | 15 елдан артык | 4,0 |

Эш стажын үзгәрткәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү) стажны раслаучы документлар оешмада булса, эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ия булган көннән яки стажны раслый торган кирәкле документ бирелгән көннән башкарыла.

26. Квалификация категориясе өчен түләүләр тариф-квалификация характеристикасы нигезендә һөнәри-квалификация төркемнәре киселешендә аттестация нәтиҗәләре буенча квалификация категорияләрен бирүне күздә тоткан белгечлекләр буенча мәгариф оешмалары мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

монда:

$B_{kk}$ - квалификация категориясе өчен түләүләр;

$O_d$-аерым мәгариф оешмаларының медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$-квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме 7 нче таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (оешма) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

7 нче таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме

| Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 3,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 6,0 |
| Югары квалификация категориясе | 10,0 |
| Табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 6,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| Югары квалификация категориясе | 20,0 |

27. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd},$$

монда:

$B_{sd}$-эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;

$O_d$-аерым мәгариф оешмаларының медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sop}$- эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме.

Эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме 8 нче таблицада китерелгән.

Әлеге оешмада, бүлекчәдә һәм вазыйфаларда конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлек үзенчәлекләренә өстәмәләр билгеләнә торган хезмәткәрләр вазыйфалары исемлеге һәр оешмада сайлаулы профсоюз органы яки хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен якларга вәкаләтле оешма белән килештереп раслана.

8 нче таблица

Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләрнең тәкъдим ителүче күләме

| Тәртип номеры | Эшчәнлек үзенчәлеге өстәмә түләү билгеләү өчен нигез | Һөнәри-квалификация төркеменең исеме | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | Мәгариф оешмаларында эш | урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 17,0 |
| | | табиблар һәм провизорлар | 10,0 |

28. Дәүләт бүләкләре иясе булган өчен түләүләр аерым мәгариф оешмаларының медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

монда:

$B_{pz}$-дәүләт бүләкләре өчен түләүләр;

$O_d$-аерым мәгариф оешмаларының медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$-дәүләт бүләкләре өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автономмяле республикалар әүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикалар дәүләт бүләкләре өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Медицина хезмәткәрләренә түләүләр бирә торган дәүләт бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасында китерелгән.

Дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү күләмен билгеләү дәүләт бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләкләре булган хезмәткәрләргә түләү, хезмәткәр сайлавы нигезендә, шуларның берсе буенча билгеләнә.

29. Аерым мәгариф оешмаларының медицина хезмәткәрләренә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр, профиль буенча эш дәвамлылыгына карап, һөнәри-квалификация төркемнәре киселешендә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

монда:

$B_s$-профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$-аерым мәгариф оешмаларының медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$-профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме 9 нчы таблицада китерелгән.

9 нчы таблица

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме

| Һөнәри-квалификация төркеменең исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Табиблар һәм провизорлар | 3 елдан 5 елга кадәр | 5,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 7,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 9,0 |
| | 15 елдан артык | 10,0 |

Эш стажын үзгәрткәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү) стажны раслаучы документлар оешмада булса, эш стажы өчен

түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ия булган көннән яки стажны раслый торган тиешле документ бирелгән көннән башкарыла.

27. Эшчәнлек интенсивлыгы өчен түләүләр медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sr} = O_d \times D_{sr},$$

монда:

$B_{sr}$ - интенсив хезмәт өчен түләүләр;

$O_d$-аерым мәгариф оешмаларының медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sr}$ - хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләү күләме.

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләү күләме 10 нчы таблицада китерелгән.

10 нчы таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр күләме

| Һөнәри-квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмәләр диапазоны, процент |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | өченче | 3,0 |
| | бишенче | 5,0 |
| Табиблар һәм провизорлар | беренче-икенче | 3,0 |

31. Аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләренә юбилей даталары, аерым хөрмәтләү билгеләре, Рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу сәбәпле һәм оешманың локаль актлары һәм күмәк килешүләре белән билгеләнгән башка нигезләр буенча пермияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре төп эш урыны һәм төп вазыйфасы (укытучы-дефектолог, укытучы-логопед (логопед) вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) буенча аерым вакыт (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.

Эш йомгаклары буенча премиаль һәм башка кызыксындыру түләүләренең күләме, тәртибе һәм шартлары оешманың локаль актлары һәм күмәк килешүләре белән билгеләнә.

Аерым мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә премиаль түләүләргә каралган хезмәт өчен түләү фонды төп эш урыны һәм төп вазыйфалары буенча хезмтәкәрләргә (укытучы-дефектолог, укытучы-логопед, логопед вазыйфаларыннан тыш) окладлар (хезмәт хакы ставкалары, вазыйфаи окладлар) түләүгә, аудиториядән тыш эш һәм кызыксындыру характерындагы түләүләргә каралган хезмәт хакы фондының кимендә 2 процентын тәшкил итә.

32. Аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләренә аерым вакытта башкарылган эш

нәтиҗәләре өчен  түләүләр төп эш урыны буенча билгеләнә (укытучы-дефектолог, укытучы-логопед (логопед) вазыйфаларыннан тыш). Аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләренә башкарылган эшнең сыйфаты өчен түләүләргә йогынты ясаучы төп критерий булып эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү тора.

Аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары Башкарма комитет белән килешенеп оешма җитәкчесе тарафыннан раслана. Аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлар,  түләүләрне гамәлгә кую шартлары  оешма алдына куелган бурычлар нигезендә ел саен билгеләнә.

33. Аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләренә башкарыла торган эшләрнең күләме, тәртибе һәм шартлары оешманың локаль норматив актлары һәм коллектив килешүләре белән билгеләнә.

34. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kj} = \frac{FOT_k}{\sum_{i=1}^{n}\sum_{j=1}^{m}\left(I_{ij} \times K_i\right)} \times \sum_{i=1}^{n}\left(I_{ij} \times K_i\right),$$

монда:

$B_{kj}$- j-хезмәткәргә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләү;

$FOT_k$-башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүгә каралган хезмәт өчен түләү фонды;

$I_{ij}$-j-хезмәткәрнең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең нормалаштырылган i критерие;

$K_i$-эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының i-авырлык коэффициенты;

n-эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары саны;

m-аерым мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең саны.

35. Эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийларын нормалаштыру төрле үлчәмдәге нәтиҗәлелек критерийларының чагыштырмасын тәэмин итә. Нормалаштыру - эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критерие (иң яхшысы һәм начары) күрсәткечләре диапазонын сайлап алудан гыйбарәт, аларның берсе нормалаштырылган критерийның нуль , икенчесе - бердәнбер мәгнәсенә туры килә Нәтиҗәлелек критериеның  факттагы күрсәткече диапазон чикләрендә булганда, эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие нульдән берәмлеккә кадәр зурлыкны ала. Нәтиҗәлелек критериеның фактик мәгънәсендә иң начар күрсәткечтән түбәнрәк булган очракта, нормалаштырылган критерийның әһәмияте нульгә тигез, иң яхшы күрсәткечтән югары булганда - берәмлеккә тигез.

36. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие зурлыгының эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие зурлыгына бәйле булуы турыдан-туры (уңай

динамика критерийның зурлыгын арттыру белән билгеләнә) һәм тискәре (уңай динамика критерийның зурлыгын киметү белән билгеләнә) булырга мөмкин.

37. Критерий зурлыгына турыдан-туры бәйле булганда, нормалаштырылган критерий түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

монда:

$I_i$-эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең нормалаштырылган i критерие;

$FI_i$-эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериесенең факттагы зурлыгы;

$M_i$ - эффектив эшчәнлек критериесенең иң яхшы зурлыгы;

$L_i$-эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериесенең иң начар зурлыгы.

37. Критерий зурлыгына турыдан-туры бәйле булганда, нормалаштырылган критерий түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = 1 - \frac{FI_i - L_i}{L_i - M_i},$$

монда:

$I_i$-эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең нормалаштырылган i критерие;

$FI_i$-эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериесенең факттагы зурлыгы;

$M_i$ - эффектив эшчәнлек критериесенең иң яхшы зурлыгы;

$L_i$-эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериесенең иң начар зурлыгы.

39. Эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критериесенең өстенлекле дәрәҗәсе авырлык коэффициентлары белән билгеләнә. Иң өстенлекле критерийга иң зур коэффициент бирелә. Чагыштырма авырлык коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_i = \frac{VK_i}{\sum_{i=1}^{n} VK_i},$$

монда:

$K_i$--эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең i критерие-чагыштырма үлчәм коэффициенты;

$VK_i$- эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең i критерие үлчәм коэффициенты.

40. Аерым мәгариф оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик күләме 11-13 нче таблицаларда китерелгән.

11 нче таблица

Мәгариф хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме

| Тәртип | Вазыйфаның исеме | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|

| номеры | | |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1.Беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналның һөнәри-квалификация төркеме | | |
| 1.1. | Уку бүлеге секретаре | 5 |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналның һөнәри-квалификация төркеме | | |
| 2.1. | Кече тәрбияче | 35 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| 3.1. | Физик культура буенча инструктор | 45 |
| 3.2. | Музыка җитәкчесе | 45 |
| 3.3. | Педагог-оештыручы | 50 |
| 3.4. | Социаль педагог | 50 |
| 3.5. | Тәрбияче | 55 |
| 3.6. | Методист | 55 |
| 3.7. | Педагог-психолог | 55 |
| 3.8. | Өлкән инструктор-методист | 55 |
| 3.9. | Өлкән методист | 60 |
| 3.10. | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | 60 |
| 3.11. | Укытучы-дефектолог | 60 |
| 3.12. | Укытучы-логопед (логопед) | 60 |
| 4. Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| 4.1. | Структур бүлекчә мөдире (җитәкчесе): гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү белем бирү программасын гамәлгә ашыручы кабинет,лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-производство) остаханәсе һәм башка структур бүлекчәләр (икенче квалификация дәрәҗәсенә караган структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш), | 65 |

12 нче таблица

## Мәгариф хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме

| Тәртип номеры | Вазыйфаның исеме | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1.Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1.1. | Аккомпаниатор | 35 |
| 1.2. | Мәдәни оештыручы | 35 |
| 1.3. | Түгәрәк, һәвәскәрләр берләшмәсе, клуб җитәкчесе | 35 |
| 2. Әйдәүче звено мәдәният хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри-квалификация төркеме | | |
| 2.1. | Китапханәче | 40 |
| 2.2. | Тавыш операторы | 40 |

13 нче таблица

## Медицина хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме

| Тәртип номеры | Вазыйфаның исеме | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| 1.1. | Медицина регистраторы | 35 |
| 1.2. | Шәфкать туташы | 40 |
| 1.3. | Массаж буенча шәфкать туташы | 40 |
| 1.4. | Өлкән шәфкать туташы | 50 |
| 2. Табиб һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| 2.1. | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәсенә караган табиб-белгечләрдән тыш) | 60 |

41. Аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелегенең типлаштырылган критерийлары Башкарма комитет тарафыннан раслана.

42. Аерым мәгариф оешмаларында башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр фонды формалаша, аның күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT_k = FOT_{do} \times D_k,$$

монда:

$FOT_k$-башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүгә каралган хезмәт өчен түләү фонды;

$FOT_{do}$ - аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең төп эш урыны буенча вазыйфаи окладлар (окладлар, хезмәт хакы ставкалары) буенча хезмәт өчен түләү фонды (укытучы-дефектолог, укытучы-логопед, логопед, укытучы-дефектолог вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш);

$D_k$-хезмәт өчен түләү фондының кызыксындыру характерындагы түләүләр өлеше

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләү өчен хезмәткә түләү фондының тәкъдим ителгән күләме төп эш урыны буенча (укытучы-дефектолог, укытучы-логопед (логопед) эшләүче хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары (окладлары, хезмәт хакы ставкалары) буенча аерым мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фондының 5 проценты күләмендә кабул ителә.

## 4 бүлек. Компенсация характерындагы түләүләр

43. Аерым мәгариф оешмаларының мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләренең компенсация характерындагы түләүләренә түбәндәгеләр керә:

1) зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән хезмәткәрләргә түләү;

